**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Верхнестярлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл жирлеге Советы БАШЛЫГЫ**

ул. Советская д.32г, с. Верхнее Стярле, 423314
Азнакаевского муниципального района
Тел. (8-85592) 42-6-18 факс (8-5592) 42-6-18
VSt.Azn@tatar.ru

Совет урамы, 32г, Югары Стәрле авылы, 423314
Тел.факс (8-85592) 42-6-18
VSt.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «07» ноября 2025 г. № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең Түбән Стәрле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнен бердэм системасында жирле узидарэне оештырунын гомуми принциплары турында» 2025 елнын 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законының 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле узидарэ турында» 2004 елның 28 июлендэге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл жирлеге Уставы нигезендэ, карар бирэм**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең Түбән Стәрле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Билгеләргә :

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең Түбән Стәрле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты - 2025 елның 20 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны- Түбән Стәрле авылы, Кызыл таң ур., 42а йорт, Түбән Стәрле авылы клубы ;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә.:

- 2025 елның 7 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге

Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә.:

Түбән Стәрле авылы, Кызыл таң ур., 42а йорт;

- сайлау хокукына ия Түбән Стәрле торак пунктында яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Түбән Стәрле торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, моңа:

- 1 һәм 2 төркем инвалидлар;
- көндезге бүлектә укучы студентлар;
- махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзалары;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнар;

һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (ком-вак таш катнашмасын сатып алу, төяү, ташу, салу, Кызыл таң урамындагы юлны профильләштерү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http//aznakayevo.tatarstan.ru һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: ТР, Азнакай муниципаль районы, Югары Стәрле авылы, Совет ур., 32 Г.; Азнакай муниципаль районы, Түбән Стәрле авылы, Кызыл таң ур., 42 а йорт.; ТР, Азнакай муниципаль районы, Түбән Стәрле, Кызыл таң ур., 19 йорт.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә..

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: Л.С.Сабирҗанова